ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«25» октябрь 2021 ел №1088

**«Спорт мәктәпләренең һәм балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларының матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 24 августындагы 625 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алына торган керем күләмнәрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнар күләмнәрен арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Спорт мәктәпләренең һәм балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларының матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 24 августындагы 625 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Арча Арена» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе буенча 1 нче кушымтада бәя турындагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Халыкның категориясе | Йөрүнең дәвамлылыгы, сәгать | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Прокатка тимераяклар бирү | Яшь буенча чикләүсез | 1 | 30 |
| 2 | Шугалакта шуу | Өлкәннәр һәм 9 яшьтән олырак | 1 | 100 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | балалар | | |
| | | 9 яшькә кадәрге балалар | 1 | 50 |
| 3 | Шугалакны прокатка бирү | Корпоратив шуу | 1 | 3000 |
| | | Читтән килүчеләр | 1 | 3000 |
| | | Арча МР һәм Арча шәһәре халкы өчен | 1 | 2000 |
| 4 | Тимераякны кайрау (бер пар) | Өлкәннәр | | 100 |
| | | Өлкәннәр (ярышлар вакытында) | | 150 |
| | | 16 яшькә кадәрге балалар | | 50 |
| 5 | Душ | | 30 минут | 20 |
| 6 | Шугалакны прокатка алган вакытта өстәмә киенү-чишенү бүлмәсе белән тәэмин итү | Шугалакны арендалаучылар өчен | 1 | 500 |
| 7 | Хоккей матчын карау | Шугалакны арендалаучылар өчен | 1,5 | 30 |
| 8 | Хоккей турнирын карау | Шугалакны арендалаучылар өчен | 1 көн | 50 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов